КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 4 февраль г.Казань № 67

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер актларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 февраль, 116 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 848 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 953 нче; 2021 ел, 16 август, 725 нче; 2023 ел, 20 февраль, 166 нчы; 2023 ел, 27 апрель, 532 нче; 2023 ел, 14 август, 975 нче; 2023 ел, 8 ноябрь, 1442 нче; 2024 ел, 29 июнь, 479 нчы; 2024 ел, 10 декабрь, 1128 нче; 2025 ел, 24 май, 353 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «1 724 861,0» саннарын «1 897 360,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәнең 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Министрлык тарафыннан коллегия төзелә, аның төп бурычы – дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле мөһим мәсьәләләр буенча карарлар әзерләү. Коллегия составына министр, аның урынбасарлары, шулай ук башка затлар, шул исәптән Министрлыкның структур бүлекчәләре, ведомство буйсынуындагы учреждениеләр җитәкчеләре, дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә өлкәсендә вәкаләтле органнар, башка республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләре, Министрлыкның Иҗтимагый советы рәисе, оешмалар, шул исәптән фәнни оешмалар җитәкчеләре керә.

Коллегия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

Коллегиянең рәисе министр була.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составын һәм әгъзалары санын раслау турында» 2019 ел, 24 декабрь, 1189 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 702 нче; 2021 ел, 18 август, 741 нче; 2022 ел, 14 гыйнвар, 13 нче; 2022 ел, 3 октябрь, 1064 нче; 2023 ел, 19 гыйнвар, 22 нче; 2023 ел, 16 май, 597 нче; 2023 ел, 23 август, 1001 нче; 2024 ел, 30 декабрь, 1280 нче; 2025 ел, 22 июль, 541 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составын раслау турында»;

1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

3. Бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 1 пунктындагы икенче абзацы гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 24 декабрь, 1189 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 4 февраль, 67 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы коллегиясе
составы

| | |
|---|---|
| Начвин Илья Сергеевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры, коллегия рәисе |

Коллегия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Багров Юрий Николаевич | «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры |
| Габдрахманов Булат Фәнил улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Дьячков Виктор Васильевич | «АйСиЭл – КПО ВС» акционерлык җәмгыятенең Директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Едельсков Алексей Евгеньевич | «Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры |
| Кузнецова Регина Викторовна | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Мәхмүтов Илнур Нәваил улы | «Россия почтасы» акционерлык җәмгыятенең «Татарстан почтасы» федераль почта элемтәсе идарәсе директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Метшин Айдар Рәис улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча) |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Нуретдинов Айрат Рәфкать улы | «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Огородников Алексей Игоревич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы |
| Халәпов Альберт Айрат улы | «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хөсәенов Рәгать Галиәгъзам улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Яковлев Альберт Валерьевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары. |

_______________________________